ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Красновидово авылы
тел. 8 (843 77) 2 04 13

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Красновидовского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Красновидово
тел. 8 (843 77) 2 04 13

# КАРАР

**2020 елның 30 гыйнварындагы** **1номерлы**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР бирде**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегендә 1 нче һәм 2нче кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2020 елның 1 февраленнән билгеләргә һәм гамәлгә кертергә .

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең

гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 5 апрелендәге 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Красновидово авылы, Совет ур., 4;
ТР, Кама Тамагы районы, Бортас авылы, Үзәк ур., 3;
ТР, Кама Тамагы районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитетының
Красновидово авыл җирлеге Башлыгы В. П. Оленин

Кама Тамагы
муниципаль районы Красновидово
авыл җирлеге Башкарма
комитетының
2020 елның 30 гыйнварындагы
1номерлы карарына
1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе-*( сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3670,18 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 522,27 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Кама Тамагы
муниципаль районы Красновидово
авыл җирлеге Башкарма
комитетының
2020 елның 30 гыйнварындагы
1номерлы карарына
2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе-*( сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 188,35 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3481,83 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 522,27 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |